ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.10.2024 с.Старое Дрожжаное № 434

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, авыл җирлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләү шартларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 09 апрелендәге 170 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) “Үзәкләштерелгән бухгалтерия” муниципаль казна учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы нигезләмәдә, 1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |

| | | |
|---|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 33 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 31 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш хисапчы) | | 31 500 |
| Бүлек начальнигы | 27 700 | 27 700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 25 300 | 25 300 |
| Бухгалтер | 24 000 | 24 000»; |

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә 1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Вазифа | Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары халык саны белән | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 25 700 | 27 000 |
| Бухгалтер | | 24 500». |

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, авыл җирлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары хезмәте өчен түләү шартларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июнендәге 263 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасында әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов